| | | |
|---|---|---|
| “Каралды”<br>МБ җитәкчесе:<br>____/Гаффарова Д.В./<br>Беркетмә №1,<br>“24 ” август 2023 ел. | “Килешенде”<br>Уку-укыту эшләре буенча<br>директор урынбасары:<br>______/Гыйбадуллина З.Ш./<br>“25” август 2023 ел. | “Раслыйм”<br>Директор:<br>____/Ибраһимова Д.М./<br>Боерык №187,<br>“25 ”август 2023 ел |

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «Д.Г. ХӘКИМОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТҮБӘН МӘТӘСКӘ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ» НЕҢ ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯЛЕ ТАТАР ТЕЛЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ УКЫТУЧЫСЫ ГАБДРАХМАНОВА НАИЛӘ ШАЙНУР КЫЗЫНЫҢ “ТУГАН ЯК МУЗЕЕ” ТҮГӘРӘГЕ ПРОГРАММАСЫ

Йөрүчеләрнең яше – 11-14 яшь

Программа 1 елга исәпләнә

2023-2024 нче уку елы

## Аңлатма язуы

“Туган як музее” түгәрәге программасы гомуми урта белем мәктәпләренең 5-8 нче сыйныф укучылары өчен атнага 1 сәгать исәбеннән төзелде. Барлыгы 34 сәгать.

**Программаның максаты:** укучыларны музей эшенә өйрәтү, экскурсоводлар әзерләү буенча беренчел мәгълүмат бирү; музейда экспозицияләрне яңарту.

**Бурычлар:** - укучыларны кече яшьтән музей профиле буенча эшләргә, экскурсовод булырга әзерләү;

- Бөек Ватан сугышында катнашкан авылдашларыбызның сугышчан юлын өйрәнү аша халкыбызның тиңдәшсез батырлыгына хөрмәт уяту;
- тарихи чыганаклар белән эш һәм музей экспонатларын саклау, конференцияләрдә чыгыш ясау, кирәкле мәгълүмат эзләү һ̓ем табу, экскурсияләр үткәрү күнекмәләрен булдыру һәм камилләштерү;
- тарихи шәхесләрнең эш-гамәлләренә аңлатма бирү, чагыштыру, анализлау, тормыш юлларын өйрәнү аша аларга карата үз мөнәсәбәтеңне билгели белү;
- түгәрәк эшендә укучыларның шәхси сыйфатларын, коммуникатив, иҗади сәләтләрен ачу;
- укучыларның танып-белү күнекмәләрен, кызыксынуларын үстерү; балаларда үз халкына, тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә карата кызыксыну уяту, үз милләте тарихына, яшәешенә битараф булмаска өйрәтү.

## Программаның эчтәлеге

Түбән Мәтәскә урта мәктәбенең “Туган як» этнографик музее бел̓ен танышу.
Музей төрләре; туган якны өйрәнү, сугышчан Дан, тарихи; дәүләтнеке, районныкы, шәхси, мәктәп музейлары.
Тарихи чыганаклар. Газета, журналлар, китаплар.
Тарихи чыганаклар. Хатирәләр, хатлар, фотолар.Тарихи чыганаклар бел̓ен эш алымнары.
Тарихи чыганаклар. Арча районы тарихына багышланган китаплар
Тарихи чыганаклар. Авыллар турында истәлекләр. Архив материаллары.
Бөек Ватан сугышы турындагы материаллар. Музей экспонатларының тарихы.
Музейның экспозицияләре белән танышу. Экспозиция төзү үзенчәлекләре
Музейда булган экспонатларга характеристика биреп карау.
Кем ул экскурсовод? Экскурсовод булу серләренә төшенү.
Беренче экскурсияне алып бару.
Бөек Ватан сугышы. Укучыларга сугыш китергән бәла-казаларны, илебезнең зур югалтуларын аңлату. Татарлар арасындагы беренче Советлар Союзы Геройлары белән танышу.
Арча районыннан чыккан Советлар Союзы Геройлары турында мәгълүмат бирү. Бөек Ватан сугышы елларында авылым тарихы.
Авыл тарихына караган истәлекл̓ерне, хатларны, китапларны уку.
Безнең ветераннар. “Хәтер” китабыннан һ̓ем “Мемориал” сайтыннан алар турында мәгълүмат эзләү.
Авылымнан чыккан данлыклы кешеләр.
“ Минем гаиләмдә данлыклы кеше” темасына иҗади проект әзерләү.
Музей түгәрәге эшчәнлегенә нәтиҗә чыгару.

## Планлаштырылган нәтиҗәләр

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

- Укучыларның милли культура, нәсел җепләре, гаиләләре турында мәгълүматлы булуы.
- Сөйләү осталыгын гамәли үзләштерүе.
- Укучыларның сыйныф, мәктәп күләмендә узган чараларда актив катнашуы.
- Укучыларның төрле сәхнәләштерелгән тамашаларда катнашуы.
- Үз туган ягыңның сәнгать кешеләре турында тулы мәгълүмат алу.
- Практика белән теорияне кушып, тулыландыра алу мөмкинлеге булу.

**Шәхси нәтиҗәләр**:

- Укучының җаваплылык хисен активлаштыру.
- Укуга һәм хезмәткә уңай мөнәсәбәт булдыру.
- Баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү.
- Әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү.
- Төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү.
- Гаилә белән мәктәп арасында җылы мөнәсәбәт урнашу.
- Милли тәрбия нигезләрен аңлавы.
- Туган як белән кызыксынуларын үстерү һәм мәхәббәт тәрбияләү.
- Туган ягыбыздан чыккан геройлар, әдипләр, күренекле кешеләр белән кызыксыну һәм алар белән горурлану хисләре тәрбияләү.

**Календарь – тематик планлаштыру**

| № | Тема | Сәгать саны | Эшчәнлек төре | Вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **План** | **Факт** |
| 1 | Кереш. Музейның эш планы белән танышу | 1 | Музейның экспозиция-ләре, экспонатлары, оешу тарихы белән танышу. Актив сайлау | | |
| 2 | Музей төрләре. | 1 | Музей төрләрен аңлау | | |
| 3 | Тарихи чыганаклар. Газета, журналлар, китаплар. | 1 | Тарихи чыганаклар белән эш алымнары булдыру | | |
| 4 | Тарихи чыганаклар. Хәтирәләр, хатлар, фотолар. | 1 | Тарихи чыганаклар белән эш алымнары булдыру. | | |
| 5 | Тарихи чыганаклар. Арча районы тарихына багышланган китаплар | 1 | Китаплары белән танышу. | | |
| 6 | Тарихи чыганаклар. Авыллар турында истәлекләр. | 1 | Архив материаллары белән танышу. | | |
| 7 | Практикум. Тарихи материаллар белән эш. | 1 | Мөстәкыйль эш күнекмәләре булдыру | | |
| 8 | Бөек Ватан сугышы турындагы материаллар. | 1 | Музей экспонатларының тарихы белән танышу | | |
| 9 | Музейның экспозицияләре | 1 | Музейның экспозиция-ләре белән танышу. | | |
| 10 | Практикум. “Экспозиция төзү үзенчәлекләре” | 1 | Экспозиция төзү үзенчәлекләре белән танышу. | | |
| 11 | Музей экспонатлары | 1 | Музей экспонатларын өйрәнү. | | |
| 12 | Практикум. Музейда булган экспонатларга характеристика | 1 | Музейда булган экспонатларга харак-теристика биреп карау. | | |
| 13 | Кем ул экскурсовод? | 1 | Экскурсовод булу серләренә төшенү. | | |
| 14 | Практикум “Мин-экскурсовод!” | 1 | Беренче экскурсияне алып бару. | | |
| 15 | Бөек Ватан сугышы | 1 | Укучыларга сугыш китергән бәла-казаларны, илебезнең зур югалтуларын аңлату. | | |
| 16 | Бөек Ватан сугышы | 1 | Сугыш вакытындагы авыл тормышын өйрәнү. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 17 | Бөек Ватан сугышы | 1 | Сугыш вакытындагы мәктәп тормышын өйрәнү. | | |
| 18 | Бөек Ватан сугышы | 1 | Сугыш чоры балалары белән танышу. | | |
| 19 | Татарлар арасындагы беренче Советлар Союзы Геройлары. | 1 | Советлар Союзы Геройлары юлын өйрәнү. | | |
| 20 | Татарлар арасындагы беренче Советлар Союзы Геройлары. | 1 | Советлар Союзы Геройлары юлын өйрәнү. | | |
| 21 | Арча районыннан чыккан Советлар Союзы Геройлары | 1 | Арча районыннан чыккан Советлар Союзы Геройлары турында лекция тыңлау. | | |
| 22 | Бөек Ватан сугышы елларында авылым тарихы. | 1 | Җитәкче лекциясен тыңлау | | |
| 23 | Практикум. Авыл тарихына караган истәлекләр, хатлар, китаплар | 1 | Авыл тарихына караган истәлекләрне, хатларны, китапларны уку | | |
| 24 | Безнең ветераннар. | 1 | Авылыбыз җирлегеннән сугышка киткән солдатларны искә алу. | | |
| 25 | Практикум. “Хәтер” Китабы һәм “Мемориал” сайты | 1 | Безнең ветераннар турында мәгълүмат эзләү. | | |
| 26 | Практикум. “Хәтер” китабы һәм истәлекләр белән эш | 1 | “Хәтер” китабы һәм истәлекләр белән эш күнекмәләре булдыру. | | |
| 27 | Практикум. “Солдат хатларында дары исе” | 1 | Солдат хатларын уку. | | |
| 28 | Авылымнан чыккан данлыклы кешеләр. | 1 | Авылдан чыккан данлыклы кешеләр турында сөйләү. | | |
| 29 | Практикум. Авылымнан чыккан данлыклы кешеләр. | 1 | Авылдан чыккан шәхесләр турында мәгълүмат табу | | |
| 30 | Сугыш чоры кешеләре белән очрашу. | 1 | Сугыш чоры кешеләре белән очрашу үткәрү. | | |
| 31 | Бөек Җиңү бәйрәме | 1 | Бөек Җиңү бәйрәменә әзерлек. | | |
| 32 | Бөек Җиңү бәйрәме | 1 | Бөек Җиңү бәйрәмендә катнашу. | | |
| 33 | “Минем гаиләмдә данлыклы кеше” темасына иҗади проект әзерләү. | 1 | Проект ясау | | |
| 34 | Проект яклау | 1 | Һәр төркем “Минем гаиләмдә данлыклы кеше” темасына үзләре әзерләгән проектларны яклыйлар. | | |

**Файдаланылган әдәбият**


1. Бурлаков А.И., Похилюк А.В. О некоторых особенностях современных условий формирования патриотического сознания молодежи// Современный патриотизм: борьба идей и проблемы формирования. СПб., 2002.
2. Быков А. Организационно-педагогические вопросы патриотического воспитания в школе/ А. Быков // Воспитание школьников. – 2006. – № 6. – С. 5 – 11.
3. Военно-патриотическое воспитание на уроках истории. Методические рекомендации. – Чебоксары, 1988.
4. Кудрявцев Л.Д. Современное общество и нравственность. М., “Наука”, 2000 г.
5. Левашов В.К. Патриотизм в контексте современных социально-политических реалий//Социс, №8,2006
6. Малякова Н. Школа, где все мальчики готовятся служить в Армии / Н. Малякова // Воспитание школьников. – 2008. – № 2. – С. 12 – 15.
7. Музееведение. – М., 1998.
8. Очерки Истории Высокогорского района Республики Татарстан. – Казань: Изд-во «Мастер Лайн», 1999. – 368 с.
9. Рәкыйпов Ш. “Таңнар һаман матурмы?” Казан. Татарстан китап нәшрияты 1970. 10.Шкадов И.Н. “Озеро Хасан. Год 1938”. Москва, 1988.